ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.02.2021 № 79

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 гыйнварындагы 74 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнгән Р. М. Гибатдиновның бәяләмәсе нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән эшләү буенча иҗтимагый Координация советы турында» 2018 елның 29 гыйнварындагы 74 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада 5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5.9. Совет утырышы нәтиҗәләре буенча рәис һәм җаваплы сәркатип тарафыннан имзаланган утырыш беркетмәсе төзелә. Совет беркетмәсен рәсмиләштерү вакыты-өч эш көне эчендә».

2 нче кушымтада 5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Яшьләр координация Советы карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә, беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, алар Совет рәисе яисә аның рәислек урынбасары тарафыннан утырышта имзалана. Совет әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Совет утырышларында рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора».

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының.2021 елның 5 февралендәге 79 номерлы карарына 2 нче кушымта

Яшьләр координация Советы составы

| | |
|---|---|
| Л.М. Нәфыйгина | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Яшьләр координация Советы рәисе; |
| Р.М. Фәтхетдинова | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы, Яшьләр координация Советы рәисе урынбасары; |
| А.Н. Рәхмәтуллина | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы, Яшьләр координация Советы рәисе урынбасары; |
| К.С.Копонева | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге баш белгече, Яшьләр координация Советы секретаре |
| Совет әгъзалары: | |
| Р.И. Әхмәдиева | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Ч.З. Газизова | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы урынбасары; |
| Э.Р. Лещенко | Нурлат муниципаль районының «Балалар иҗат үзәге» өстәмә белем бирү МБУ директоры (килешү буенча); |
| Р.М. Елауркина | «Бердәм Россия Яшь гвардиясе» оешмасының Нурлат бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| А.С. Билданова | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре үзәге» МБУ директоры (килешү буенча); |
| М.Ю. Сычев | Яшьләр парламенты рәисе (килешү буенча); |
| Г.В. Ганиева | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| С.Н. Липатова | Балалар иҗтимагый оешмасы вәкиле (килешү буенча); |
| О.Г. Терентьева | Нурлат районында һәм Нурлат шәһәрендә Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау |

| | |
|---|---|
| | министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Л.М. Мөбарәкшина | «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасының баш мөхәррире (килешү буенча); |
| И.И. Гыймадиев | «Г.С. Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» МБУ директоры (килешү буенча); |
| М.И. Белов | «Ледок» хоккей буенча спорт мәктәбе» МАУ директоры (килешү буенча) |